**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«12» ноябрь, 2018 ел Кече Шилнә авылы № 46/1

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Советының 2012 елның 7 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең генераль планын раслау хакында» 11/1 санлы карарын гамәлдән чыгару турында

Тукай районы прокуратурасының 2017 елның 8 июнендәге 02-08-03 санлы күрсәтмәсе нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законга, РФ Шәһәр төзелеше кодексына, авыл җирлеге уставына таянып,Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Советының 2012 елның 7 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең генераль планын раслау хакында» 11/1 санлы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе А.Г. Даутов